КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 июль г.Казань № 624

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 23 ноябрь, 961 нче; 2012 ел, 15 май, 378 нче; 2014 ел, 11 июнь, 398 нче; 2014 ел, 27 ноябрь, 920 нче; 2015 ел, 17 апрель, 259 нчы; 2015 ел, 14 декабрь, 946 нчы; 2018 ел, 24 июль, 593 нче; 2019 ел, 16 сентябрь, 834 нче; 2020 ел, 16 май, 395 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибендә (алга таба – Тәртип):

2.2 пунктта:

«в» пунктчада татар текстында «үзенчәлекләре» сүзеннән соң «, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә дәүләт хезмәтен күрсәтү вариантларын үз эченә алырга тиеш, гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә әлеге хезмәтне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары, шул исәптән алар файдалану өчен мөрәҗәгать иткән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләренә карата да булырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

«е» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Административ регламентның структурасында мәгълүмат технологияләре өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә, мәгълүмат технологияләрен кулланып, тиешле хезмәт күрсәтү процедураларын автоматлаштыруны тәэмин итә торган мондый хезмәт күрсәтү процедураларының машина белән укып була торган тасвирламасы каралырга тиеш.»;

2.3 пунктның «в» пунктчасындагы өченче абзацында «шулай ук башкарма хакимият органының, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында, шулай ук «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4 пунктның беренче абзацында «Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләпнең исеме», «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге», «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графалары булган таблица рәвешендә рәсмиләштерелә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктның «б» пунктчасында «15 көн» сүзләрен «биш көн» сүзенә алмаштырырга.

2. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләүне һәм раслауны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 2021 елның 30 декабренә кадәр дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын Тәртип (бу карар редакциясендә) таләпләренә туры китерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин